АССОЦИАЦИЯ
«СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНЫХ
ОБРАЗОВАНИЙ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН»

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘРЕ
СОВЕТЫ»
АССОЦИАЦИЯСЕ

РЕШЕНИЕ ПРЕЗИДИУМА **ПРЕЗИДИУМ КАРАРЫ**

от 12.03.2020 № ПР-163-5

г. Казань

«Татарстан Республикасының елның иң яхшы якташлыгы» Республика конкурсы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнехановның күрсәтмәсен үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы якташлар җәмгыятьләре арасында үткәрелгән конкурста җиңүчеләрне бүләкләү күләмен арттыру турында йөкләмәсен үтәү йөзеннән, якташлар һәм якташлыклар арасындагы элемтәләрне ныгыту һәм киңәйтүгә, халык тормышының социаль-икътисади, мәдәни һәм башка мәсьәләләрен хәл итүдә ярдәм итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне активлаштыру максатыннан чыгып:

1. «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы» Ассоциациясе президиумының 2009 елның 13 маендагы ПР-133-1 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы елның иң яхшы якташлыгы» республика конкурсы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы» Ассоциациясенең башкарма сәркатибенә йөкләргә.

Рәис **Ә.С.Гобәйдуллин**

«Татарстан Республикасы муниципаль
берәмлекләр Советы» Ассоциациясе
президиумы карары белән
Расланган
«12» 03 2020 № ПР-163-5

«Татарстан Республикасының елның иң яхшы якташлыгы» Республика конкурсы турында нигезләмә

Казан 2020

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә «Татарстан Республикасының елның иң яхшы якташлыгы» республика конкурсын (алга таба – Конкурс) оештыру һәм үткәрү тәртибен билгели.

1.2. Нигезләмә Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы Законнары, «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы» Ассоциациясе Уставы (алга таба – Совет), Совет Президиумы карарлары нигезендә эшләнгән.

1.3. Конкурсның төп максатлары:

Татарстан Республикасында якташлар җәмгыятьләре эшчәнлеген активлаштыру;

Татарстан Республикасында якташлар җәмгыятьләренең инициативаларына ярдәм итү;

халык тормышының социаль-икътисадый, мәдәни һәм башка мәсьәләләрен хәл итүдә ярдәм күрсәтү өчен якташлар һәм якташлыклар арасындагы элемтәләрне ныгытуны һәм киңәйтүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән Татарстан Республикасы якташлыкларының эшчәнлеген стимуллаштыру.

1.4. Конкурсны үткәрү йомышлары:

Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округларының иң актив һәм эшлекле якташлык җәмгыятьләрен ачыклау һәм аларга ярдәм итү;

якташлыкларның уңай тәҗрибәсен ачыклау һәм тарату.

1.5. Нигезләмә Совет Президиумы тарафыннан раслана.

1.6. Конкурста Казан һәм Яр Чаллы шәһәрләре территориясендә үз эшчәнлекләрен гамәлгә ашыручы муниципаль районнар һәм шәһәр округлары якташлыклары катнаша ала.

1.7. Конкурста жиңүчеләрне билгеләгәндә төп критерийлар - якташлык җәмгыятьләренең нәтиҗәле һәм актив эшчәнлеге, халыкка якташлар җәмгыятьләренең эше турында мәгълүмат бирү, муниципаль берәмлекләр белән уртак программаларны гамәлгә ашыру эше, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге муниципаль берәмлекнең рәсми сайты яки бите булу.

1.8. Конкурста жиңүчеләр - якташлар җәмгыятләре Совет исеменнән дипломнар һәм акчалата бүләк белән бүләкләнә.

II. Төп төшенчәләр

2.1. Гариза - конкурста катнашу өчен кирәкле документлар пакеты.

2.2. Акчалата бүләк - Татарстан Республикасының иң яхшы якташлыкларын бүләкләү максатларында конкурс йомгаклары буенча бүлеп бирелә торган акчалар.

2.3. Катнашучы - Казан шәһәре һәм Яр Чаллы шәһәре территориясендә үз эшчәнлеген башкаручы Татарстан Республикасының якташлыгы.

2.4. Конкурста I, II һәм III урыннарны алган Татарстан Республикасы якташлыклары.

III. Бәйгене үткәрү тәртибе

3.1. Конкурсны үткәрү өчен оештыру комитеты (алга таба - оештыру комитеты) төзелә, аның составы Совет Президиумы тарафыннан раслана (1 нче кушымта).

3.2. Конкурсны үткәрү вакыты оештыру комитеты тарафыннан раслана.

3.3. Оештыру комитеты утырышы аның составының яртысыннан артыгы булганда тулы вәкаләтле. Карар ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә һәм оештыру комитеты әгъзаларының кимендә 50 проценты аның өчен тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала. Тавышлар тигез булган очракта рәислек итүче тавышы хәлиткеч булып тора.

3.4. Оештыру комитеты:

– конкурста катнашу өчен гаризалар кабул итү һәм теркәүне гамәлгә ашыра;

– гаризаларны алдан сайлап алуны гамәлгә ашыра;

– конкурста җиңүчеләрне билгели (тәкъдим ителгән материалларны алдан бәяләү өчен эксперт төркемнәре җәлеп ителергә мөмкин);

– конкурста җиңүчеләрне тантаналы бүләкләү оештыра;

- массакүләм мәгълүмат чараларында конкурс үткәрү һәм аның нәтиҗәләре турында мәгълүматларны бастырып чыгаруны тәэмин итә.

3.5. Конкурс белән бәйле барлык документларны саклауны Совет каршындагы Якташлар җәмгыятьләренең Координацион советы сәркатибе башкара.

3.6. Гариза үз эченә ала:

- әлеге Нигезләмәнең 2 нче кушымтасы нигезендә конкурста катнашу турында гариза;

– әлеге Нигезләмәнең 3 нче кушымтасы нигезендә якташлык эшчәнлеге турында мәгълүмат;

- альбом-презентация (слайдлар рәвешендә).

Конкурста катнашучының гаризасы бары тик электрон рәвештә генә Советның җаваплы хезмәткәре адресына тапшырыла.

3.7. Конкурста катнашу өчен гаризалар кабул итү һәм теркәү эш көннәрендә исәпләнгән көннән 10 көн эчендә оештыру комитеты каршында оештырыла торган эшче төркем гамәлгә ашырыла.

3.8. Эшче төркем, гаризалар кабул итү тәмамланганнан соң, эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көнлек вакыт эчендә, гаризаларны бәяләү критерийлары нигезендә, әлеге Нигезләмәнең 3 нче кушымтасы нигезендә балл системасы буенча бәяли.

3.9. Бәяләү нәтиҗәләре буенча баллар җыю тәртибендә Казан һәм Яр Чаллы шәһәрләрендәге якташлар җәмгыятьләре эше буенча ике рейтинг төзелә.

3.10. Оештыру комитеты җиңүчеләрне һәр катнашучы җыйган балларның йомгаклау суммасыннан чыгып, Казан һәм Яр Чаллы шәһәренең Якташлар җәмгыятьләренең һәр төркеме буенча билгели.

3.11. Акчалата бүләкләрнең гомуми суммасы 4 (дүрт) миллион сум тәшкил итә: үз эшчәнлекләрен Казан һәм Яр Чаллы шәһәрләре территориясендә гамәлгә ашыручы муниципаль районнар һәм шәһәр округлары якташлары өчен 2 әр миллион сум, алар түбәндәгечә бүленә:

I урын өчен - бер призлы урын -600 мең сум;

II урын өчен - ике призлы урын – 400 мең сум;

III урын өчен - өч призлы урын – 200 мең сум.

3.12. Оештыру комитеты утырыш беркетмәсен төзи, конкурста җиңүчеләрне дипломнар һәм акчалата призлар белән бүләкләү турында Карар кабул итә. Йомгаклау утырышы беркетмәсенә оештыру комитеты рәисе һәм оештыру комитеты секретаре кул куя.

3.13. Конкурста җиңүчеләр акчалата призны якташлык Уставы (нигезләмәсе) нигезендә якташлык җәмгыяте яки идарә итү органы карары нигезендә якташлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кулланалар.

3.14. Җиңүчеләр әлеге Нигезләмәнең 5 нче кушымтасы нигезендә акчалата призны куллану турында хисаптан соң килүче елның 1 апреленә кадәр советка тапшыралар.

IV. Йомгаклау нигезләмәләре

4.1. Мөрәҗәгать итүче Оештыру комитеты карарларына Совет президиумына шикаять бирергә хокуклы.

4.2. Конкурска җибәрелгән документлар Советта ике ел дәвамында саклана.